КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 ноябрь г.Казань № 1416

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 28 февраль, 137 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 28 февраль, 137 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 март, 176 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәдә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин